**КАРАР**

**«08» ноябрь 2025 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Яңа Ключище авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, нигезендә 2025 елның 08 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Яңа Ключище авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 5000 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 10000 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чишмәне ремонтлау материаллар сатып алу,буяу, алып кайту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (аншлаг урнаштыру, материаллар сатып алу, алып кайту һәм буяу);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 6 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 6 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 5 кеше тавыш бирде;

“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 1 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлегендә Яңа Ключище авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Яңа Ключище авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 5000 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 10000 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чишмәне ремонтлау материаллар сатып алу,буяу, алып кайту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (аншлаг урнаштыру, материаллар сатып алу, алып кайту һәм буяу);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.
“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Яңа Ключище авылы, Мир урамы, 1 нче йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин